## Марсель Гыймазетдинов






**КАЗАН**
**ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ**
**1990**

## БУЛ ХУҖАСЫ ТЫНЫЧЛЫКНЫҢ, ҖИРЕМ!

**Утлы кылыч белән күкне телеп**
**Яшьни-яшьни, шаулап, күкрәп,**
**Килеп җитте менә тагын язым —**
**Хуш исләргә тулды күкрәк.**
**Энҗе тамчы булып яуды яңгыр,**
**Чәчте нурын Кояш-асыл.**
**Бәрхет чирәмнәрдә иркәләнеп**
**Уйный егерменче гасыр.**
**Тансык моңнар — кош-корт авазлары,**
**Бар табигать уйный моңлы сазын.**
**Кочагына алды камышлыклар**
**Сагынып кайткан үрдәк-казын.**
**Санап булмый**
**Җирнең изгелеген.**
**Ул нарасый, садә, түзем.**
**Зиһеннәре томаланса кешелекнең һәм капланса әгәр күзе,**
**Күчәреннән чыгуы бар Җирнең.**
**Аек акыл кирәк җирдә шуңа...**
**...һәр ел саен килсен язлар.**
**Үрдәкләрен көтсен камышлары,**
**Камышларын сагынып кайтсын казлар.**
**Яңгыр яусын энҗе бөртек булып,**
**Чәчсен нурын Кояш-асыл.**
**Йомшак басып хәтфә чирәмнәрдән**
**Килсен утызынчы гасыр.**

## ТУГАН ҖИРНЕҢ КИТМӘС КОШЛАРЫ БЕЗ*

**Чәчәкле җәп үтте,**
**Моңсу көзләр җитте —**
**Очар кошлар китте тезелеп,**
**Һаваларда очкан,**

**Зәңгәр күкне кочкан**
**Кошлар кебек идек без элек.**

**Очар кошлар очсын,**
**Зәңгәр күкне кочсын —**
**Ә без калыйк туган төбәктә.**
**Туган җирнең яме —**
**Яшәешнең тәме,**
**Тамыр җәйгән безнең йөрәктә.**

**Яшел язлар җирдә,**
**Сагыну моңы җилдә —**
**Киткән кошлар кайта ашкынып.**
**Гел яшисе килә,**
**Бер яшьнисе килә —**
**Җанга тула бәхет ташкыны.**

**Язгы күкрәү кебек,**
**Яздай карыйк көлен —**
**Эреп аксын салкын кышлары.**
**Без — җилкенеп очкан,**
**Зәңгәр күкне кочкан,**
**Туган җирнең китмәс кошлары,**
**Яз ясаучы китмәс кошлары.**

***Фирзор Мортазин музыкасы**

## КАЙТАМ

**Сагындыра,**
**Сагындыра икән**
**Сабый чакның керсез көннәре.**
**Яшьлегемнең хатирәсе итеп**
**Саклап йөрттем айлы төннәрен.**

**Авылыма бүген кире кайтам,**
**Калды инде шәһәр юллары.**
**Юксындылар инде, басуларны**
**Иген игеп үскән кулларым.**

**Изге җирне сөрим,**
**Иген игим,**
**Малкайларны йөртим көтүдә.**
**Ниләр җитә күңел тарткан җирдә**
**Авылыңда гомер итүгә.**

**Бөтенләйгә кайтам,**
**Киткән чакта**
**Гафу итче, авылым, кимсетсәм.**
**Кабул ит син мине, кабул итче,**
**Инде башка синнән мин китмәм.**

## ИГЕНЧЕНЕ ЗУРЛЫЙМ

**Авылымда тудым, авылымда үстем,**
**Беркая да аннан китмәдем.**
**Күкрәгемә терәп кисәм бүген**
**Үзем иккән арыш икмәген.**

**Тартканнарны шәһәр тартсын әйдә,**
**Мин мәңгегә җиргә бәйләнгән.**
**Арыш серкә очыруы минем**
**Күңелемдә җырга әйләнгән.**

**Мин игенче, игенчене зурлыйм**
**Басуларны иңләп кайтышлый Буразнадан башка**
**тора алмыйм,**
**Игенчегә**
**Барлык җырларымны багышлыйм.**

## ТУГАН АВЫЛЫМ

Синең белән кавышуны
Мин сагынып көтеп алам.
Камышлар курай тарта да
Күңелгә моңнар сала.

Җырдан тынмый чишмәләрең,
Инешләрең — ил яме.
Зәңгәр күктән тургай җырын
Туялмыйча тыңладым.

Урманыңда кәккүкләрең
Эндәшә гомер санап.
Мин үлемсез бугай синдә —
Туктамый кәккүк һаман.

## ҖИРЕМӘ

Күккә мендем җирдән аерылып,
Диңгезләргә киттем ярлардан.
Сагышларым кире алып кайтты,
Мин бит шушы җирдә яралган.

Туфрагында,
Үләнендә аунап,
Чишмә суын эчеп үскәнмен.
Истән чыкмый Кармантау буенда
Дуслар белән маллар көткәнем.

Әрәмәдә
Гөләп, балан җыйдым,

Күрәннәрен чаптым сазлыкның.
Дусай күлләрендә дуслар белән
Алтыннарын сөздек балыкның.

Күл суында пешкән балыкларның
Их, тәмле дә була шулпасы...
Мәңгелеккә
Җиргә береккәнмен,
Ник омтылам җиргә шул чаклы?

Тарту көчең бардыр синең, бәлки,
Мин бит сиңа һаман тартылам.
Әгәр, Җирем,
Барыр җирең булса,
Мин китәрмен синең артыңнан.

## АК КАЕННАР

Минем туган якларымда гына
Шулай шаулый кебек каеннар.
Алар арасында зарыгып көткән,
Без утырткан бер пар каен бар.

Менә бит ул безнең яшьлегебез —
Чуклы шәлен салган иңенә.
Рәхәтләнеп бөдрә чәчен тарый
Туган якның назлы җилендә.

Ак каеннар шаулап үсә һаман,
Икебез дә аңар гашыйк без.
Ул гүзәлләр җирдә назланганда,
Бәхет күкләренә ашыйк без...

Мөлдерәмә тулгап күңел күле,
Шатлык булып җиргә ташыйк без...

## САГЫШЛАРНЫ БАСА АЛМАМ

**Торган җир әйбәт булса да,**
**Яхшырак туган якта.**
**Авылымның таңнары да**
**Үзгә, үзгәрәк ата.**

**Яшьли йөргән сукмаклардан**
**Килә тагын үтәсе,**
**Айлы кичтә күл буенда**
**Хыялларны сүтәсе.**

**Күктә балкый түгәрәк ай,**
**Шәүләсе төшкән суга.**
**Сагынып гомерем үтәрме,**
**Сагышка калдым шуңа.**

**Сагышларны баса алмам,**
**Кайтмыйча туган якка.**
**Алтыннарга күмелсәң дә,**
**Авылым үзенә тарта.**

**...Ак томаннарга төренеп,**
**Тездән чык ярып кайтам.**
**Сагышларым — якты сагыш —**
**Гомеремне озайта.**

*******

**Коймак пешәдер мичләрдә**
**Төтен чыгара өйләр.**

**Алсу таңнар атып килә,**
**Тарала таныш көйләр.**

**Хезмәт көе, хезмәт җыры**
**Яңгырый таңнар белән.**
**Иркен болын кочагыннан**
**Нур ярып кайтып киләм.**

**Төне буе атлар көттек,**
**Бергә-бергә ай белән.**
**Җәйге таңнар әйтерсең лә**
**Яшьлектән кире килгән.**

**Яшьлегемдәге тургайлар,**
**Яшьлектәге болыннар,**
**Яшьлектәге арыш кыры,**
**Яшьлектәге — колыннар.**

**Тик аерма фикерләүдә,**
**Аерма бар караштa.**
**Аерма бар яшьләрдә дә**
**Башкарак уйлар башта.**

**Күп нәрсәдә бар аерма —**
**Үтелгән байтак гомер...**
**Картайсам да янам әле,**
**Күңелем — утлы күмер.**

## АВЫЛ ЧИШМӘСЕ

**Авылымның чылтыр чишмәсе бар,**
**Чәйгә суы бигрәк килешә.**
**Таңнар белән шунда суга килә**
**Алсу, Банат, Сара һәм Гайшә.**

**Авыл карты аны тәрбияләп,
Карап торды гомере буена.
Рәхәтләнде авылымның халкы
Җанга рәхәт татлы суына.**

**...Күптән түгел шул чишмәгә килдем:
Таш-кирпечтән чишмә киенгән.
Тирә-ягы яшел рәшәткәле,
Тал-тирәкләр аңар иелгән.**

**Йөрәк тибәмени!
Салкын суы
Бәреп тора ап-ак ташыннан.
Кем төзәткән? —
Шуңа рәхмәт әйттем,
Түбәтәем салып башымнан.**

**Авылымның чылтыр чишмәсе бар!
Көч-хәл өсти эчсәң сулары.
Шул чишмәдә очрашадыр кебек
Кешеләрнең гомер юллары.**

## АЛТЫН КӨЗЕМ

**Җиргә төшә сары, ал яфраклар,
Көз җиткәнен алар белдерә.
Алтын көзең синең, туган ягым,
Күңелемә якын, бер генә.**

**Басуларым инде бушап калган:
Икмәкләре кергән амбарга.
Алтын көзем.
Ямансулый алмыйм,
Юксына да алмыйм син барда.**

**Һәркайда да муллык, кызыл туйлар,**
**Һәрбер җирдә күзге шатлыклар.**
**«Кара көз» дип сиңа беркем әйтмәс,**
**Кочагыңда муллык, байлыклар.**

**Хуш киләсең, әйдә, алтын көзем,**
**Көтеп алдык кыш, яз, җәй аша.**
**Безнең язмыш килер язмышларга**
**Шундый көзләр аша тоташа.**

**ТУГАН ЯГЫМ**
**(Җыр)**

**Юллар йөрү олы шатлык миңа,**
**Дөнья күреп, илләр гизәм мин.**
**Туган яктан ераклашкан саен**
**Тарту көчен күбрәк сизәм мин.**

**Туган якның искән җилләре дә,**
**Камыш шаулавы да кадерле.**
**Синдә чакта гына, туган ягым,**
**Белмибез күк синең кадерне.**

**Юл йөрүдән, ил гизүдән кайткач,**
**Аунадым мин йомшак чирәмдә.**
**Сагыну канатында очып кайтам,**
**Китсәм әгәр ерак җирләргә...**

**Юллар йөрү олы шатлык мина —**
**Мин дөньяны ничә әйләндем!**
**Юл йөрүләр миңа шатлык булса,**
**Синдә яшәү — үзе бәйрәмдер...**

## ИЛЕМ ТАҢЫ

**Чулпан йолдыз батты, таңнар атты,**
**Якты нурлар җирне аклады.**
**Уяндылар кырлар, яңгырады җырлар,**
**Сандугачлар таңны мактады.**

**Мәрҗән сыман көмеш таң чыклары**
**Чәчәкләрне кочып үптеләр.**
**Җирнең иминлеген барлагандай,**
**Талгын җилләр исеп үттеләр.**

**Ал кояш та керфекләрен ачып**
**Гәүһәр нурын сипте үрләргә.**
**Бүз тургайлар назлы моңнар илтте**
**Төнбоеклы көмеш күлләргә.**

**Күбәләкләр кырга китә очып,**
**Бал кортлары — матур болынга.**
**Ни җитә соң туган як таңына,**
**Мактыйм шуны җырлар җырымда.**

## ТИРӘКЛӘРЕМ

**Инеш буенда тирәкләр**
**Моңланып уйга талган.**
**Яшел читле сукмакларда**
**Яшьлекнең эзе калган.**

**Шул эзләр мине һаман да**
**Чакырып, әйдәп тора.**
**Яшьлек ул мәңге үзгәрмәс**
**Чәчәкле җәйдә тора...**

**Тирәкләре дә яшьлекнең**
**Гел уңмый, яшел төсле.**
**Шаян яшьлек, кыңгыраудай,**
**Челтерәп дәшәр төсле.**

**Кайттым.**
**Инде сукмакларны**
**Үләннәр баскан икән.**
**Тирәкләр кебек иелгән,**
**Ул сезнең башлар икән.**

**Тирәкләр танымый бугай,**
**Ятсынып карап тора.**
**Көмештәй якты сулар да,**
**Нигәдер кара тора...**

**Озак йөрелде бугай шул,**
**Озак йөрелде бугай.**
**Туган якның хәтереннән**
**Чыгадыр кеше шулай.**

**Аңладым соңлап:**
**Мин монда**
**Шаулыйсы тирәк икән.**
**Бу җирдә тамыр җәяргә,**
**Яшьлегемнең тирәкләре,**
**Сез миңа кирәк икән!..**

## ГОМЕРЛӘРНЕҢ ШАУЛЫ ЯЗЛАРЫ

**Бүрәнәгә тезелеп утырганнар —**
**Ялкыткандыр кышкы суыклар...**
**Туеп булмас иде бу язлардан**
**Шушы җирдә мең кат туып та...**

**Челтер-челтер аккан чишмә моңын**
**Күңел мең кат отып алгандыр.**
**Бөтерелеп искән йомшак җилләр**
**Шул моңнарны җанга салгандыр...**

**Ишетелә алкын инешкәйнең**
**Салмак кына җырлап агуы.**
**Буразнага ятып мең тыңланган**
**Җир-ананың сулыш алуы...**

**Армас-талмас кыр җырчысы — тургай**
**Җырлый мактап күктә яз аен.**
**Иңбашына яшел өрфия шәл**
**Салган әнә нәфис яшь каен...**

**Күл буенда уйчан тал-тирәкләр**
**Башкайларын суга игәннәр.**
**Ябалдаш 1ы наратларның башы**
**Әйтерсең лә күккә тигәннәр...**

**Басуларда дулкын-дулкын уҗым,**
**Сулыш алган иркен болыннар.**
**Яз шатлыгын тоеп, араннарда**
**Чабып йөри нәни колыннар.**

**Сабыйлары җирдә тәгәрәшә,**
**Үлән чүпли тавык-казлары.**
**Картларга да яшәү алып.килә**
**Гомерләрнең шаулы язлары.**

**Бүрәнәгә тезелеп утырганнар —**
**Ялкыткандыр кышкы суыклар...**
**Туеп булмас иде бу язлардан**
**Шушы җирдә мең кат туып та...**

## БАЛАЧАК РӘСЕМЕ

Ясап куйдым ап-ак кәгазьгә мин
Ал кояшны алсу буяу белән.
И, әбием бер сөенсен әле —
Рәсемемне бүлмәсенә әләм.

Сөйгән әбиемнең бүлмәсенә
Көлтә-көлтә нурлар тулсын әле.
Шул нурларга карап, әбиемнең
Сөенечтән күңеле булсын әле.

Мин кояшны ясыйм бик күп итеп,
Әтиемә, әниемә бирәм.
Кояш нурларына чумсын әйдә,
Бөтен авыл, бөтен күрше-тирә.

Кояшлар күп булсын, әйдә, җирдә,
Кояш нурларына тулсын илем.
Ал буявым, ап-ак кәгазьләрем
Һич бетәрлек түгел әле минем...

## КӨТ СИН, АНА

Тан, әтәче кычкыра дүртенче кат,
Сукты сәгать инде дүрт тапкыр.
Танга карап, ана улын көтә,
Син кайгырма, ана,
Ул кайтыр.

Хәбәр килми, диеп үпкәләмә,
Бәлки, юктыр вакыты язарга.
Авыргандыр,
Белгертәсе килми,
Ышан, кайтыр шушы язларда.

**Туган җирдән, әниләрдән башка,**
**Ни ямь бар сон, әйтче, бу җирдә?**
**Үпкәләмә, ана,**
**Рәнҗемә дә ана,**
**Кайтыр әле улын бер таңда.**

**Күкрәк сөтен бирдең,**
**Авырлыкны җиңдең,**
**Кыенлыклар аша атладың.**
**Син дә шулай**
**Улың,**
**Илдән башка**
**Иң газизне җирдә тапмадың.**

**Ана,**
**Бала,**
**Халкым,**
**Туган җирем.**
**Бер-берсенә алар бәйләнгән.**
**Аерып булмый,**
**Давыл,**
**Ут,**
**Су белән**
**Көйгә салган җырга әйләнгән.**

**...Таң әтәче кычкыра бишенче кат,**
**Сәгать сукты янә биш тапкыр.**
**Юлга чыгып ана улын көтә,**
**Көт син, ана,**
**Тиздән ул кайтыр.**

## ХӘБӘР КӨТӘМ ҺАМАН

**Каршы чыгам, иркәм,**

Кайтыр юлларыңа.
Сагыш хисе тулы
Чәчәк кулларымда.

— Көт мине, көт,— дидең,
Чәчләремнән сөйдең.
Үзең белән алдың
Йөрәгемне минем.

Язмышта ни язган:
Яшьлек көтеп узган.
Көттем сине көздән,
Көттем кыштан, яздай.

Саубуллашкан көннән,
Узган кырык бердән.
Хәбәр көтәм синнән,
Хәбәр көтәм җилдән,
Хәбәр көтәм җырдан,
Хәбәр көтәм җирдән,
Ник кайтмыйсың, иркәм?..
Каршы чыгам көн дә
Киткән юлларыңа.
Сөю хисе тулы
Чәчәк кулларымда.
Шул гөлләрне учлап
Сибәм юлларыңа:
Киткән юлларыңа,
Кайтыр юлларыңа...

## ӘЙЛӘНЕП КАЙТТЫЛАР

Җырланып бетмәгән җырлар бар,
Сөйләшеп бетмәгән сүзләр бар.
Сөрелеп бетмәгән җирләр бар,

**Сөелеп туймаган күзләр бар.**

**Өзелеп-өзелеп көтеп тә**
**Кавыша алмаган ярлар бар —**
**Ядрәдән киселгән егетләр**
**Җир кочып егылып калганнар.**

**Шул җирдә калыккан чәчәктән**
**Болыннар, үзәннәр балкыйлар.**
**Әйтерсең гөл булып батырлар**
**Өйләргә әйләнеп кайттылар...**

## ТАЛЬЯН ГАРМУН

**Кулларымда тальян гармун чыңлый —**
**Әтиемнән калган истәлек.**
**— Зур үс, улым, тальянымны сакла,**
**Бу гармунда минем хисләрем,—**

**Дигән сүзе тальян моңы кебек,**
**Колагымда тора гел минем.**
**Иртә-кичен шуны көйлимен мин,**
**Аннан моңлы көйне белмимен.**

**Тальян гармун озата барды яуга,**
**Тальян гармун тылда уйнады.**
**Тальян гармун Җиңү маршын көйләп,**
**Урамнарны иңләп-буйлады.**

**Сагынганда алам кулларыма,**
**Шул тальянны сузам кичләрен.**
**Чишмәләрдәй көмеш моңы сөйли**
**Әтиемнең кайнар хисләрен.**

## КЫЗЛАР. КЫЗЛАР

*Ватан сугышы чоры кызларына*

**Кызлар, кызлар,**
**Сезгә ни әйтсәм дә,**
**Бик аз булыр төсле күренә.**
**Комбинезон кигән буй-сыныгыз**
**Зифа талдай калды күңелдә.**

**Тракторын йөртте,**
**Иген икте,**
**Бары җиңү булды уенда.**
**Арган күңелләргә дәрт өстәлде,**
**Кичен кызлар килгән уенга.**

**Кызлар, кызлар,**
**Үтте яшьлегегез**
**Фермаларда,**
**Завод,**
**Кырларда.**
**Сөю сүзен сез бит ишеттегез**
**Ул чакларда бары җырларда.**

**Кызлар, кызлар,**
**Җиңү язы килде.**
**Ир-егетләр яудан кайттылар.**
**Тик кайтмады узган яшьлегегез,**
**Агым судай агып киттеләр.**

**Кызлар, кызлар!**
**Сезгә ни әйтсәм дә,**
**Бик аз булыр кебек күренә.**
**Каршы чыгып көткән чакларыгыз —**
**Ак каендай калды күңелдә.**

**Рәхмәт сезгә, кызлар!..**

## ӘНКӘЙГӘ

**Ник кайтмый соң, ул-бу юк микән, дип,**
**Борчыласың, әнкәй тагын да.**
**Бүген дә мин туган нигеземә**
**Кайтам, әнием, синең янына.**

**Таныш миңа капка ачылуы,**
**Ишек шыгырдавы күптәнге.**
**Улым кайты, диеп, бик тиз генә**
**Самоварын куеп җибәрде.**

**Учагында дөрләп утын яна,**
**Каз итеннән шулпа өлгерә.**
**Сыйлыйм әле төпчек улымны, дип**
**Арлы-бирле әнкәй йөгерә.**

**Утыр әле, әнкәй, яннарыма,**
**Сине күргәч, ашау онтыла.**
**Ни хәлең бар?**
**Ачуланма инде,**
**Сирәк кайтам туган йортыма.**

**Сәламәтлек ничек, сөйлә, әйдә,**
**Тавышыңны зармын тыңларга.**
**Оныткан, дип рәнҗи күрмә берүк,**
**Сине уйлыйм туар таңнарда.**

**Менә, әнкәй, салкын кыш та үтте,**
**Сандугачлы язлар килделәр.**
**Тургайларсыз язлар булмаган кук,**
**Һәрчак синдә безнең күңелләр.**

## ЗУР КӨРӘШТӘ ӘЛЕ БҮГЕН ДӘ

**Басуларым — арыш дулкыннары,**
**Болыннарым — чәчәк бәйләме.**
**Күптәнме соң дөнья бәйрәм итте**
**Сагынып көткән Җиңү бәйрәмен.**

**Күптәнме соң дөнья бәйрәм итте,**
**Ә күптәнме җирләр тетрәде?**
**Һәркем белә: сугыш теләүчеләр**
**Җир йөзендә әле бетмәде.**

**Көрәшәбез, изге җиребезне**
**Үлем, хәсрәт, каннар күммәсен.**
**Яралары сызлап торган җирем**
**Сугыш афәтләрен күрмәсен.**

**Алсу таңнар сызылып атсын диеп,**
**Кояш көлсен өчен күңелдә.**
**Яралары сызлап торган җирем**
**Зур көрәштә әле бүген дә.**

## ЧҮКЕЧ ЧЫҢЫ

**Аргы урамнан чың-чаң, чың-чаң —**
**Ишетелә чүкеч чыңы.**
**Шул авазлар хәтерләтә**
**Чабаталы балачакны.**

**Алачыкта без, сабыйлар,**
**Чиратлашып күрек тарттык.**
**Шул чүкечнең чыңнарыннан,**
**Моңнарыннан ләззәт таптык.**

**Төрәннәрен сукаларның**
**Таптый иде олы чүкеч.**
**Сандалларда чың-чаң итеп**
**Җырлый иде кече чүкеч.**

**Балачакта чүкеч чыңы**
**Күңелләргә сеңеп калган.**
**Чың-чаң, чың-чаң.**
**Шул чыңнарны**
**Бүген менә җырга салам.**

## ТУГАН ЯК КӨЗЕ

**Алтынсу төс усак, каеннарда,**
**Басуларда сыр-сыр буразна.**
**Болыннарда чабып йөри җилләр —**
**Хәйран калып тордым беразга...**

**Күзләремдәй мөлдерәмә күлнең**
**Җилләр үбә җырчы камышын...**
**Күргән сыман булам мин шуларда**
**Гомеремнең кайтмас агышын.**

**Кыр казлары кайтыр, әнә алар**
**Саубуллашып китеп баралар.**
**Миләшләрем кызыл тәлгәшләрен**
**Яулык сыман болгап калалар.**

**Ә мин калыр идем яшел җәйдә,**
**Кояш нурларына ябышып.**
**Көзләр белән тиңләп буламени —**
**Башкарак шул кеше язмышы...**

**Табигать гел алмашынып тора,**

**Язлар белән тагын яшәрер...**
**Туган җирнең фасыллары белән**
**Мин яшәрмен, мәңге яшәрмен.**

## ЯЗГЫ ҖЫРЛАР

**Тын алан, зифа каеннар,**
**Көмеш күл җәйрәп ята.**
**Тал-тирәкләр яфрак яра,**
**Шомыртлар чәчәк ата.**

**Яшел үлән арасыннан**
**Тар тасма сукмак уза.**
**Җиһанның барча кошлары**
**Язгы, дәртле җыр суза.**

**Һәрбер җирдә яз шатлыгы,**
**Һәр җирдә язгы җырлар.**
**Коена назлы көйләрдә**
**Урманнар, тугай, кырлар.**

**Мин дә кушылам җырларга,**
**Күңелкәем җыр тели.**
**Язгы көннәр, якты көннәр —**
**Оҗмах шул түгелмени!**

## ТӘРӘЗӘДӘ НИЛӘР БАР?

**Төнге тынлык.**
**Биш катлы йорт.**
**Тәрәзләрдә ут яна.**
**Шатлык тулы бер тәрәздәи**

**Жыр тарала дөньяга.**

**Бер тәрәздән оран сала**
**Яна туган нарасый.**
**Якты көнгә күз салгандай,**
**Утка текәлгән сабый.**

**Бер тәрәздә кайгы уты —**
**Куя кеше дөньяны...**
**Тәрәзәләр нидер сөйли,**
**Тик анлыйбызмы аны?..**

**Тәрәзләрдә якты утлар —**
**Уйлар уйларны сүтә:**
**Кемдер килә, кемдер китә,**
**Ә яшәү дәвам итә.**

## ХУШ КИЛӘСЕҢ, ЯҢА ЕЛ!

**Авырлыклар калсын иске елда,**
**Килеп торсын бу ел җиңеллек.**
**Муллык булсын,**
**Дус-иш артып торсын,**
**Күкләр аяз булсын ип элек.**

**Басуларда иген шаулап үссен,**
**Бакчаларда — алсу алмалар,**
**Һәр йорт саен шатлык алып килсен**
**Яңа елда туган балалар.**

**Нәфис гөлләр үссен болыннарда,**
**Урманнарда кәккүк моңлансын.**
**Җир шарына иркен тормыш килсен,**
**Тик сугышлар гына булмасын.**

**ҮКЕНМӘМ**

**Һич үкенмәм,**
**Кыя түбәсенә әгәр**
**Менеп җитеп,**
**Еракларга,**
**Еракларга күңелем белән**
**Очып китеп,**
**Күрә алсам,**
**Йөрәк белән тоя алсам**
**Халкым моңын,**
**Кайгы, сагыш,**
**Шатлыкларын...**

**Үткән эздән**
**Сызылып калды**
**Ак сукмагым...**
**Бер салынган**
**Сукмак инде**
**Һич күхмелмәс.**
**Түгелсен тир,**
**Ул сукмакны салыр өчен**
**Бөгелсен бил,**
**Болар өчен**
**Үкенмим гел.**

**Тап-тар гына**
**Булсын әйдә**
**Сызган юлым.**
**Салган юлны**
**Тоя, дуслар,**
**Күнелем минем.**
**Йөрәгем дә әйтә кебек:**
**Мен кыяга.**
**Күзең ташла еракларга,**

**Еракларга!**
**Күңелең керсез,**
**Үткән юлың авыр булсын,**
**Туры булсын —**
**Халкың белән бер аяктан,**
**Шул сукмактан**
**Гел атларга.**

## ТОЛЫМБАЙ

**Казахларга дала канат куя —**
**Ут уйнатып куа чаптарын...**
**Азга гына уйга калам икән,**
**Искә төшә солдат чакларым.**

**Әй син, казах,**
**Якын дустым минем,**
**Килеп җитә идеп яныма.**
**Теш елтыратып,**
**Керсез елмаюың**
**Яллар бирә иде җаныма.**

**Сөйли идең:**
**Дала ни пышылдый,**
**Һавадагы тургай ни җырлый?**
**Күл буенда камышниләр сөйли,**
**Искән җилләр таңда ник елый?**

**Күл буенда камыш көйгә салган**
**Үткәннәрнең авыр газабын.**
**Киң далалар сөйли,**
**Тургай җырлый**
**Гүзәллеген мактап заманның...**

**Кулга корал тотып,**

**Сакта тордык**
**Ил чигендә бергә, Толымбай.**
**Бик дус идек,**
**Шаһит булды ана**
**Якты кояш белән Тулы ай.**

**Өч ел буе бер кашыктан ашап**
**Гомер иттек, абый-эне без.**
**Дошманнардан илне сакладык без**
**Аяз булсын өчен күгебез.**

**Казах дустым, син еракта инде,**
**Тик һаман да хатлар киләләр.**
**«Татар дустым,**
**Күнелләрем сине**
**Сагына шул бигрәк,— дияләр.—**

**Кил кунакка,**
**Кымыз,**
**Мәйләр белән,**
**Бишбаомаклар белән сыйлармын.**
**Уйлыйм сине сызылып таи атканда,**
**Көтәм сине,**
**Якын туганым.**

**Көтәм симе,**
**Көтәм,**
**Килми калма,**
**Сине көтә сыйлы табыннар.**

**Язын килалмасан,**
**Көз килер дип,**
**Көтеп калган якын дустын бар.**
**Сәлам белән сиңа, Толымбай...»**

**...Казахларга дала канат куя —**
**Ут уйнатып куа чаптарын.**
**Искә төшә казах даласында**

**Тулпар атта ярсып чапканым...**

## ЮКСЫНАМ, ДИСЕҢ СИН

**Нигә соң юксынам, дисең син?**
**Әйләнеп кайт әле бу якка.**
**Гомерең уза бит,**
**Чем-кара**
**Чәчләрен буялган ап-акка.**

**Юксынып узгандыр көннәрең,**
**Сагына утырткан каеның.**
**Туган йорт нигезен күрмичә**
**Торганның күңеле кайгылы.**

**Күзләрең ямансу, боеклар.**
**Алар да авылны сагына.**
**Әйләнеп кайт әле бу якка,**
**Кайгырма, моңайма, юксынма.**

**Саф чишмә сулары, һавасы,**
**Тугае, болыны, урманы**
**Кочаклап алырлар үзеңне —**
**Шулардан кадерле җир бармы?**

**Юксынам, дисең син,**
**Гомернең**
**Саныйсы көннәре күп әле...**
**Туган як туфрагын сагынып,**
**Әйләнеп авылга кайт та син,**
**Шифалы җилләрен үп әле...**
**Ә яшәү нинди шәп — күр әле!..**

**КЕМ ИКӘН УЙЛАРЫНДА?**

**Суга бара матур кызлар,**
**Вак-вак атлап, вак-вак атлап.**
**Сукмакларда җәелеп яткан**
**Хәтфә чирәмнәрне таптап.**

**Иңнәрендә чиләкләре**
**Бик килешә буйларына.**
**Суга бара, суга алар,**
**Кемнәр икән уйларында?**

**Кайберсенең сөйгән яры**
**Армиягә китеп барды.**
**Сара,**
**Алсу,**
**Банат,**
**Зәйнәп**
**Ак яулыклар болгап калды.**

**Язган хатлар аккан сулар**
**Белән инде тиңләштеләр.**
**Банат,**
**Зәйнәп,**
**Алсу,**
**Сара**
**Бергәләшеп серләштеләр.**

**Сара әйтә:**
**Зариф мина**
**Атнага ике хат яза.**
**Хезмәт итәм отличнога,**
**Яшәп ятам исән-таза.**

**Алсу да керешә сүзгә,**
**Чөнки аның Әхмәтҗаны**
**Көн саен бер хат җибәрә,**

**Бигрәк уңган сөйгән яры.**

**Ник керешми сүзгә Банат,**
**Әллә бер-бер хәл булганмы?**
**Юк, берни булмаган аңа,**
**Тик юксына Гыйльмулланы.**

**Зәйнәбе бигрәк тә шаян,**
**Һәрбер сүзе чәнечкеле.**
**Гариф язган: «Әзерләп тор**
**Кәтлит белән чәнечкене.**

**Өйрәнеп киттем мин монда**
**Ашарга гел кәтлит кенә».**
**Зәйнәп яза җавап ана:**
**«Сау йөреп кайт, Гариф, җаным,**
**Суыртырмын кәнфит кенә».**

**Суга бара матур кызлар,**
**Вак-вак атлап,**
**Вак-вак атлап.**
**Сукмакларда җәелеп яткан**
**Хәтфә үләннәрне таптап.**

**Иңнәрендә чиләкләре**
**Килешә соң буйларына.**
**Суга бара,суга бара.**
**Әнә кемнәр уйларында.**

**ЯКТЫ ШИГЫРЬ**

**Яз кояшы җирдә.**
**Гөрләвекләр**
**Язгы ташкыи булып йөгерә.**
**Якты көннең якты бизәкләрен**

Алып була хәтта өлгегә...

Шундый вакыт бу яз: бөтен дөнья
Шатлык, сөенечкә уралган.
Күршем әнә «орчык» улы белән
Хозурланып йөри урамда.

Нарасый җан — сабый күккә карый,
Ал кояшка суза кулларын.
Ал кояшка кулын суза-суза
Үсеп килә минем улларым.

Ике улым — ике якты күзем,
Якты киләчәккә төбәлгән.
Безнең җаннар инде дүрт дистә ел
Яктылыкка карап өйрәнгән.

Үткәннәрне онытуым түгел,
Алар күңелемә уелган.
Җанга якты сирпеп, балкып тора
Ике улым минем уемда.

Дөньяда яз.
Дөнья шундый матур,
Матурлыкка бар җир уралган.
Күршем улына нидер сөйли-сөйли
Кайтып килә әнә урамнан.

Сабый бала зәңгәр күккә карый,
Ал кояшка сузып кулларын.
Әй, киләчәк!
Якты нурлар булып
Тоташалар сиңа уйларым...

СИҢА

**Нәрсә бүләк итим диеп**
**Йөрдем уйлап —**
**Йолдызларны чүпләдем мин**
**Күкләр буйлап.**

## СИҢА ӘЙТЕР СҮЗЛӘРЕМ КҮП

**Сиңа әйтер сүзләрем күп —**
**Әйтә'алмыйм,**
**Юк кыюлык.**
**Бары шуны гына анла:**
**Синнән башка**
**Тормышым юк.**

**Сина әйтер сүзләрем күп —**
**Әйтә алмыйм,**
**Сөйләр күзләр.**
**Оныта алмыйм карашыңны**
**Синең күзләр —**
**Зәңгәр күлләр.**

**Сина әйтер сүзләрем күп,**
**Җитми икән**
**Кыюлык ник?**
**Мәхәббәтем карап тора**
**Күрерме дип,**
**Танырмы дип.**

## КИЛМИСЕҢ СИН КӨЛЕП

**Таңнарда уянам,**

**Таңнарда уйланам—**
**Мин сине һаман да юксынам.**
**Көннәрем төн кебек,**
**Килмисең син көлеп —**
**Дөньяда яшәвем юк сыман...**

**Ә йөрәк сагына,**
**Уй канат кагына —**
**Җилпенеп очам мин янына.**
**Күңелдә көз кебек,**
**Килмисең син көлеп —**
**Сагыш-моң коела җаныма...**

**Юлларны күзлим мин,**
**Гел сине эзлим мин —**
**Нур тулы күзләргә яшь тула.**
**Кояшлы чык кебек,**
**Килмисең син көлеп —**
**Бер генә килсәң сон, ни була?!**

## БҮЛӘК ИТТЕМ ТАҢНЫҢ...

**Таң чыкларын иртән**
**Бүләк иттем, иркәм,**
**Алар чөнки керсез, пакь чыклар.**
**Кочып сиңа бирдем**
**Таң җилләрен җирнең,**
**Чөнки иртән җилләр саф чаклар.**

**Чәчәкләрен таннын**
**Бүләк иттем тап и,**
**Зәңгәр күзләренә мин тиңләп.**
**Көмеш күлне сина**
**Бүләк иттем, мина**
**Йөзәр өчен таңда гел иңләп.**

**Танда сайрар кошлар—**
**Тиңдәш сиңа алар,**
**Бүләк иттем аның моңнарын.**
**Барлык тойгыларым**
**Бүләк иттем танда,**
**Онытмасын, дидем, мин барын.**

**Йолдызларны күктән**
**Итмәдем мин бүләк,**
**Чөнки алар салкын, ераклар.**
**Җир җылысын бирдем,**
**Бергә булыйк, дидем,**
**Типсен бергә кайнар йөрәкләр.**

**Тан суларын алып**
**Чылтыр чишмәләрнең,**
**Бирдем сина танда эчәргә.**
**Матур гөлем, шуңа**
**Язган икән миңа**
**Синең белән тормыш кичәргә.**

## ҮПКӘЛӘ

**Булмый шул онытып язларны!**
**Язгансың сагынып аларны...**
**«Ташкыннар шикелле идең син...»**
**Укыйм мин**
**Язмышларны язганны.**

**Беренче мәхәббәт... Ярату..**
**Кирәкме яраны яңарту...**
**Яр таптың. Син киттең.**
**Мин калдым...**
**Артык күк**

**Сүз белән аңлату.**

**Кирәкми аңлату...**
**Тик бүген**
**Аңладым сөюем артканын.**
**Йөрәгем,**
**Уйларым,**
**Хыялым,**
**Күңелем гел сиңа тартканын.**

**Боларның барсын да,**
**Барсын да**
**Син дә бит күптәннән аңладың.**
**Үпкәлә!**
**Ләкин мин гаепсез.**
**Язмышны син үзен алдадың.**

## АККОШ КАНАТ КАГЫНА*

**Саргаямын сагышлардан,**
**Сәгать саен сагынам.**
**Сина сәлам илтергә дип,**
**Аккош канат кагынган.**

**Сандугачлар өзеп сайрый**
**Минем сагышларымны.**
**Барсыннар әле янына,**
**Борма аккошларымны.**

**Аккошлар сүзсез аңлаша,**
**Их, син дә аңла, иркәм,**
**Аккошлар тәрәзә кагар —**
**Ач тәрәзәңне иртән.**

**Әйтергә генә кыймыйсың,**

**Син дә сөясен, беләм.**
**Сөюеңне язып җибәр**
**Аккош канаты белән.**

***Сафьян Ибраһимоа музыкасы.***

**ЯЗЛАРНЫ КӨТӘ КҮҢЕЛ**
***(Җыр)***

**Язларны көтә күңелем**
**Әллә нигә ашкынып.**
**Давыл көткән бөркетмени —**
**Көтә язның ташкынын.**

**Язларны көтә күңелем,**
**Тик арада кышлар бар.**
**Алмагач чәчәкләредәй**
**Ява әнә ап-ак кар.**

**Язларны көтә күңелем,**
**Көтмидер идем элек.**
**Язын карлыгачлар белән**
**Син дә кайтырсың кебек.**

**Язларны көтә күңелем,**
**Юксынам сине, иркәм.**
**Сине уйлау җиңел түгел,**
**Шулай да рәхәт икән.**

**СЕРЛӘРЕҢНЕ СЕРДӘ САКЛАДЫМ**

**Серләреңне миңа сөйли идең**

**Чәчләремнән сыйпап, иркәләп.**
**Аерылганда, тик сер итеп кенә: —**
**СӨЯМ,— дидең язгы иртәдә.**

**Серләреңне мина сөйли идең**
**Унҗиде яшь ишек какканда.**
**— Сер,— дип кенә бит очымнан үптең,**
**Инешләрдә бозлар акканда.**

**Хыялландык. Истә. Оныта алмыйм**
**Кавышулар вәгъдә иткәнне.**
**Серләр калды сердә,**
**Беркем белми**
**Бер-беребезне һаман көткәнне.**

**Бүген дә мин кайтам яшьлегемә,**
**Сер саклаган туган якларым...**
**...Сөю хисе тулы йөрәк әйтә:**
**— Серләреңне сердә сакладым,**
**Серләреңне сердә саклармын.**

## ЯЗЛАР БҮЛӘК ИТТЕ

**Һәркөн саен зарыгып көтәм кичне,**
**Кич җиткәч тә — синеи килүне.**
**Язлар бүләк итте сөелүне,**
**Язлар бүләк итте сөюне.**

**Шул язларга кат-кат рәхмәт укыйм**
**Шул кичләргә мең кат табынам.**
**Сүнәр учакларым дөрләп китте —**
**Йөрәгемә утлар кабынган.**

**ГӨЛЗИРӘК**
***(Җыр)***

**Һәр язда бакчамда пар шомырт**
**Болыттай чәчәккә төренә.**
**Елмаеп, уйланып, моңаеп**
**Калдың син күңелем түрендә.**

**Үткәнгә кабаттан әйләнеп**
**Кайтырга ашкынам яңадан.**
**Әле дә сулкылдый йөрәгем**
**Яшьлектә калдырган ярадан.**

**Бернинди дарулар төзәтми —**
**Аңа бит бары тик син кирәк.**
**Кайтыр дип өзелеп көтәмен,**
**Кайт инде, күз нурым, Гөлзирәк.**

**СИН ГЕНӘ**

**Тугайларда йөрдек, шаярыштык —**
**көлдек,**
**Болыннарда хуш ис бөркелә.**
**Йөрәгемнең иң түрендә, Гөлем,**
**Бөреләндең бары син генә,**
**Күрше кызы — чибәр Гөлгенә.**

**Бакчаларда нәркис хушбуйлана,**
**Ләйсән яңгыр җиргә сибелә.**
**Мәхәббәтем чәчәк атты язда,**
**Күңелемдә бары син генә,**
**Карлыгачым минем, Гөлгенә.**

**Алтын көз дә җитте,**

**Чәчәк сулар инде,
Ак томаннар иңгә сарыла.
Иртә яздагыдай, гөлем гүзәл һаман,
Киләчәгем бары син генә,
Шаян кызый, матур Гөлгенә.**

**Күптән ап-ак һава,
Күктән мамык ява,
Тибрәлдерә аны җил генә.
Язны көтә күңелем,
Мәхәббәтем, Гөлем,
Сөенечем бары син генә,
Яшьлек дустым — гүзәл Гөлгенә.**

## АЛАЛМЫЙМ КҮЗЕМНЕ
***(Җыр)***

**Бәхеткә төренгән,
Шатлыкка күмелгән
Беренче ярату язлары.
Сагынып язларны,
Эзләп бу якларны
Тезелеп кайта кыр казлары.**

**Бар җиһан яшәрә,
Дәрт ташый яшьләрдән,
Һәркемгә яз сөю өләшә.
Яр таба ярларны,
Яз сыный аларны,
Парлардан хәтта Ай көнләшә.**

**Көнләшмә, тулган Ай,
Янында Зөһрә бар,
Бәхетле сана син үзеңне.
Сөюгә күмелгән,**

**Шатлыкка төренгән**
**Язлардан алалмыйм күземне.**

## ТӨШТӘ КҮРДЕМ

***(Миха Квливидзедән)***

**Төштә күрдем:**
**Кире кайткансың да,**
**Иркәлисең мине, үбәсең.**
**Күзләремнән мәрҗән чыклар тама,**
**Яратамын икән, күрәсең...**
**Тәмле төшне өзде телефонның**
**Чылтыравы.**
**Ниләр әйтмәдең:**
**Янадың да, куркытып та алдың,**
**Ачуландың,—**
**Бер сүз дәшмәдем.**
**Барсына да түзәргә мин риза:**
**Каргышына,**
**Сүгү, тиргәүгә.**
**Тик төшемне күреп бетерәсе иде**
**Яшьләр тамган мамык мендәрдә.**

## КҮҢЕЛЕМДӘ ШИГЕМ

***(Миха Квливидзедән)***

**Күңелемдә шик бар болыт кебек,**
**Әче җилләр исә сызгырып.**
**Кочагыма керче,**
**Җылытырмын,**
**Таңнар атар, иркәм, сызылып.**
**Хисләремдә йөз син аккош кебек,**

Серләреңне шунда ачарсың,
Хыялларны ике канат итеп,
Бәхет киңлегендә очарсың.
Йөрәгемне ачам.
Тиз кер, тиз кер инде —
Үз өеңә кергән шикелле...
...Тулган иреннәрең тараттылар
Күңелемдә туган шигемне.

## АЛСУЛЫК

Алсу тынлык кунган офыкларга,
Алсу моңга чумган эңгерләр.
Йөрәкләрне җилкендереп ала
Алсу кичтә алсу мизгелләр.

Болыннарда алсу ромашкалар
Нидер сөйли талгын җилләргә.
Алсу чыклар тамып-тамып төшә
Алсу томан кунган җирләргә.

Алсу уйлар, алсу хыял ага
Салмак кына алсу елгада.
Алсу кичләр, алсу таңнар белән
Без яшибез әле дөньяда...

Шул алсулык безнең төнебезне,
Көнебезне бергә бәйләсен.
Алсу иннек сөрткән офыкларда
Дөрләмәсен афәт шәүләсе.

## ҖЫР ЯЗДЫМ

**Сиңа дип чәчәкләр үстердем,
Зәңгәрләр — гел синең күзләрен.
Гөлләрем шау чәчәк аталар
Язларын, җәйләрен, көзләрен...
Сиңа дип шигырьләр атадым,
Иң назлы, иң татлы язларым...
Гел сина охшатып каршылыйм,
Озатам сиңа кыр казларын...
Мин сине йөрәктә саклыймын,
Әйтмичә сиңа мин, гүзәлем.
Мин сиңа җыр яздым,
Җыр яздым,
Җыр яздым сиңа мин, түзмәдем...**

## ЗӘҢГӘРЛЕГЕ СИНДӘ

**Киеп узсаң зәңгәр күлмәгеңне,
Күлдәй, күктәй булып китәсең.
Нигә инде шулай, үзәгемне өзеп,
Турыбыздан көн дә үтәсен?**

**Зәңгәрлеге синдә күгебезнең,
Зәңгәрлеге талгын суларның.
Гомер буе эчәр, сулар идем
Барлык зәңгәрлеген шуларның.**

## ӘНИСӘ*

**Зәңгәр күктә ярсып тургай җырлый,
Талгын гына язгы җил исә.
Язлар кебек матур, гүзәл дә син,**

**Сөенечем минем, Әнисә.**

**Сары шәлен ябына ак каеннар,**
**Гөлләр шиңә, алтын көз җитсә.**
**Йөрәгемдә дөрләп мәхәббәтем яна,**
**Сизәсеңме шуны, Әнисә.**

**Очып кайтыр идем, язмыш миңа**
**Яшьлегенә кире кайт, дисә.**
**Тормыш юлын бергә узарга гомергә**
**Сайлар идем сине, Әнисә.**

## ӘЙТМӘ, БЕЛӘМ

**Керфекләрең кояш нурларыдай,**
**Күзкәйләрең зәңгәр күлләрдәй.**
**Карашларың тамчы гөлләредәй,**
**Иреннәрең тулган чиядәй.**

**Кайдан алдың шундый гүзәллекне,**
**Юк бит синдәй сылу дөньяда?!**
**...Әйтмә,**
**Беләм.**
**Аның барысын да**
**Бүләк итте сиңа Җир-ана.**

**Бел кадерен җирнең...**
**Һәм үзеңнең!..**

## СОҢЛАГАН ЯЗЛАРДАЙ
***(Җыр)***

**Соңлаган язлардай килдең дә,**
**Йөрәкне хисләргә чорнадың.**
**Унҗиде яшемә кайттым мин,**
**Эзләре калса да чорларның.**

**Соңлаган язлардай килдең дә,**
**Иркәләп, моңнарда назладың.**
**Тургайлы таңнары кайткандай,**
**Бергәләп уздырган язларның.**

**Соңлаган язлардай килдең дә,**
**Канатлар үстердең, мәхәббәт.**
**Үзгәрттең язмышны, үзгәрттең,**
**Мең рәхмәт, мәхәббәт, мең рәхмәт!**

*******

**Бәхетлемен дип син бер дә һаваланма —**
**Бәхет белән хәсрәт һәрчак йөри бергә.**
**Бәхетсезмен дип син бер дә хафаланма —**
**Өйрәтә ул бәхетнең кадерен белергә.**

*******

**Исән генә кайтып җиттегезме,**
**Сагынып көткән киек казларым?..**
**Алтың көздә кызыл туйлар булды**
**Бик күпләре китте кызларның.**

**Сезнең кебек китә тора кызлар**
**Көз җиткәндә,**
**Кышлар килгәндә.**

**Тик кайтмыйлар алар,**
**Казлар кебек,**
**Кышлар үтеп, язга кергәндә.**

**Онтылмый шул!**
**Тора күз алдында**
**Чиккән яулыклары җилфердәп:**
**Кыр казлары очып кайтамени**
**Туган төбәкләргә яз эзләп!..**

*******

**Табып булмый кибетендә, базарында,**
**Тигәнме әллә шул әйбергә берәр үләт.**
**Чык базарга, астан гына сатып ята,**
**Кирәгеңне биш бәягә спекулянт.**

## ТИК КӨТӘБЕЗ КӨЗ АЕН

**Таң йолдызым, дисәм дә мин**
**Зәңгәр күктән үзгә мин.**
**Җирдә үскән роза гөлем,**
**Сине җирдән эзләдем,.**

**Кашың карлыгач канаты,**
**Күзләрең шомырт кара.**
**Көн дә очрашасы килә**
**Ерак булса да ара.**

**Билкәйләрең зифа талдай,**
**Сүзләрең юкә балдай.**
**Бөтен тынычлыгым алып**

**Ник ерак киттең алай?**

**Якынайтып araларны,**
**Күрешәбез ай саен.**
**Кавышырга вәгъдәләр бар,**
**Тик көтәбез көз аен.**

**Туйга чакырам, дусларым,**
**Парлап туйга килегез.**
**Безнең адрес үзгәрмәде —**
**Элеккечә, белегез.**

## ҖЫРЛА, ДИСЕҢ

**Җырла, дисең,**
**Җырлыйм.**
**Минем күңел**
**Җырны сөя, моңны ярата.**
**Борчуларны җырлар тарата да,**
**Шатлыкларны җырлар яңарта...**

**Сыздыр дйсен, тальяныңны,**
**Сызам,**
**Күңелләрдән моңнар түгелсен.**
**Кушыл син дә, дустым,**
**Безнең җырлар**
**Зәңгәр күккә таба үрелсен...**

**Басу-кырны урап кайтыйк әле,**
**Басулар да җырны тыңласын.**
**Безнең кырлар — безнең гомеребез,**
**Аларны да моңнар чорнасын...**

**Җырлыйк әле, дустым, җырлыйк әле,**
**Бөтен дөнья моңга күмелсен,**

**Йөрәгеңдә ята синең моңнар,**
**Син бит, дустым, моңсыз түгелсең...**

**Игенчедән шәп җырчы юк җирдә,**
**Һәм шагыйрь юк аны уздырган.**
**Синең җырың— монге бетмәс җыр ул,**
**Буразналар булып офыкларга,**
**Киләчәккә таба сузылган...**
**Җырла, дисең,**
**Җырлыйк әйдә бергә!..**